**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 49 «15» октября 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы 2018 елның 02 июленнән № 28 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 27 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү буенча Нигезләмәгә 2.10 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«б) мөрәҗәгатьне карау өчен башка дәүләт органнарындагы, җирле үзидарә органнарындагы һәм башка вазыйфаи затлардагы документларны һәм материалларны, судлардан, алдан тикшерү органнарыннан тыш, соратып алалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.А. Галеева